ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.06.2022 п.г.т.Алексеевское № 226

**«Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» халык дружинасы әгъзаларын бүләкләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, ирекле халык дружинасын кызыксындыру һәм Алексеевск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы халык дружинасының даими әгъзаларын бүләкләү максатларында

**карар бирәм:**

1. Расларга:

- «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен »халык дружинасы әгъзаларын бүләкләү турындагы Нигезләмәне (алга таба – бүләкләү) (1 нче кушымта);

- Алексеевск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы халык дружинасы әгъзаларын«Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» бүләкләү комиссиясе составын (2 нче кушымта).

2. Алексеевск муниципаль районы территориясендә, хезмәткәрләре ирекле халык дружинасы әгъзасы буларак, җәмәгать тәртибен саклауга җәлеп ителгән предприятие һәм оешма җитәкчеләренә бу карарны башкаруга кабул итәргә.

3. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен»халык дружинасы әгъзаларын бүләкләү турындагы Нигезләмәне раслау хакындагы 28.11.2018 ел № 414 нче карары үз көчен югалткан дип санарга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
07.06.2022 ел № 226 нчы карарына
1 нче кушымта

**«Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен»**
**халык дружинасы әгъзаларын бүләкләү турындагы**
**Нигезләмә**

1.«Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» халык дружинасы әгъзаларын бүләкләү (алга таба - бүләкләү) Алексеевск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы ирекле халык дружиналарын кызыксындыру һәм Алексеевск муниципаль районы оешмалары халык дружинасы әгъзаларын бүләкләү максатларында башкарыла.

2. Бүләкләү түбәндәгечә башкарыла:

2.1. Ирекле халык дружинасы әгъзасы өчен уңайлы вакытта, хезмәт хакын саклап калган көе ике өстәмә ял көне.

2.2. Алексеевск районы буенча Эчке эшләр бүлеге, Башкарма комитет җитәкчесе, район Башлыгының Рәхмәт хаты, Мактау грамотасы белән бүләкләнү;

2.3. Алексеевск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклаудагы зур казанышлары өчен акчалата эквивалентта.

3. Татарстан Республикасында хокук саклау юнәлешендәге халык дружиналары һәм иҗтимагый берләшмәләре реестрына кертелгән ирекле халык дружинасы әгъзалары бүләкләү өчен кандидатлар була.

4. Оешма һәм предприятие җитәкчеләре Алексеевск муниципаль районы территориясендә ирекле халык дружинасы әгъзасы буларак,җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы хезмәткәренә, аның өчен уңайлы вакытта ике өстәмә ял көне бирергә бурычлы,

5. Комиссия ирекле халык дружинасы әгъзаларының халык дружиннигы эшчәнлегенә кагылышлы бәхәсле мәсьәләләрне һәм каршылыкларын карый.

6. Халык дружинасы әгъзаларын нык акчалата түләү белән бүләкләү өчен Башкарма комитет карары белән раслана торган комиссия төзелә (алга таба-комиссия).

7. Халык дружинасы отряды командиры имзалаган акчалата эквивалентта бүләкләү өчен кандидатны тәкъдим итү комиссиягә ел тәмамланганчы 20 көн кала, кушымта нигезендә, форма буенча җибәрелә.

8. Комиссия үз утырышында кандидатлар буенча тәкъдимнәрне карый һәм акчалата түләү белән бүләкләү турында Карар кабул итә.

9. Комиссия үз утырышларына хокук саклау органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм халык дружинасы җитәкчеләрен чакырырга хокуклы.

10. Акчалата түләү турында карар комиссия утырышында комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

11. Карар кабул иткәндә түбәндәге категорияләр исәпкә алына:
1)халык дружинасы әгъзасының массакүләм чаралар үткәргәндә катнашуы;

2)дежурлыкка даими чыгу;
3)административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау, хокук саклау органнарына җинаятьләрне ачуда ярдәм күрсәтү.

12. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш уздырылганнан соң өч көн эчендә Комиссия рәисе һәм тавыш бирүдә катнашкан барлык әгъзалары, шулай ук комиссия секретаре тарафыннан имзалана.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
07.06.2022 ел № 226 нчы карарына
2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы халык дружинасы әгъзаларын «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» бүләкләү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Симашева Альбина Валентиновна | комиссия рәисе, Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Свистунов Игорь Константинович | комиссия рәисе урынбасары, Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча) |
| Зудина Наталья Александровна | комиссия секретаре, Башкарма комитетның опека һәм попечительство буенча баш белгече |
| Маннанов Ильшат Габдулвахитович | Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлегенең полиция участковый уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча начальнигы (килештерү буенча) |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

«Җәмәгать тәртибен
саклауда актив катнашкан
өчен» халык дружинасы
әгъзаларын бүләкләү
турындагы Нигезләмәгә
кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен » халык дружинасы әгъзаларын бүләкләүгә тәкъдим итү**

Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме ____________________________
____________________________________________________________________________
Көне, ае, туган елы ________________________________________________________
Яшәү урыны адресы _________________________________________________________
Халык дружинасы отрядының урнашкан эш урыны исеме
____________________________________________________________ Татарстан Республикасында халык дружиналары һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр реестрына кандидатны кертү датасы (көне,ае, елы)_____________________________________________________________
Эш урыны,
вазифасы _________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

**Бүләкләүгә тәкъдим ителүченең соңгы елга конкрет казанышлары күрсәтелгән характеристика:**

Халык дружинасы әгъзасының массакүләм чаралар үткәргәндә катнашуы:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________ Дежурлыкка даими чыгуы:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
__________________________________________________________________

Хокук саклау органнарына җинаятьләрне ачуда ярдәм күрсәтү:

________________________________________________________________

Башка казанышлар:

________________________________________________________________

Халык дружинасы отряды командиры________________ __________________
( имза) (ФИА.)

П.У

«____»____________20___ел.